**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге составына керүче Сәет авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

15 ноябрь 2025 ел № 1

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Сәмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең 01.11.2019 ел «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Сәмәкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «42/2 номерлы»нигезләмәне раслау хакында", нигезендә **2025 елның 15 ноябрендә** түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

“Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Сәмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнарны һәм гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират өчен материал сатып алу һәм киртә кую);

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”. »

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 95 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 49 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 49 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәет авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда яшәү урыны Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар

өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Сәмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнарны һәм гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

**-традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират өчен материал сатып алу һәм киртә кую);**

**-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокыр ремонтлау, юллар төзү, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре);» мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.**

3. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәет авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәет авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы И.М.Усманов

СЕМЕКЕЕВСКОГО
сельского поселения